## КАРАР

**“10” ноябрь 2020 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Илдус авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 10 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авы. җирлеге Илдус авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түлә күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче групп инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзар салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенч түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Зур урамының 8 нче йортыннан 10 нчы йортына кадәр юлга нигез салу һәм ва таш җәю;
- Н.Сафин урамының 10 нчы йортыннан 12 нче йортына кадәр, 3нче йортыннан 2. йортына кадәр юлга вак таш-грунттан нигез салу?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлег башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өче. җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 34 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 19 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 19 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Илдус авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.
2. «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмаба авыл җирлеге Илдус авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешег

түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләменда үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Зур урамының 8 нче йортыннан 10 нчы йортына кадәр юлга нигез салу һәм вак таш җәю;
- Н.Сафин урамының 10 нчы йортыннан 12 нче йортына кадәр , 3нче йортыннан 2Б йортына кадәр юлга вак таш-грунттан нигез салу?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Илдус авылы, Зур урам, 2 йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов